Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР №6-4

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 15 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 13.08.2018 ел №9-2 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел №236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 13.08.2018 ел №9-2 карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

нигезләмәнең 14 маддәсендәге 14.4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктчасы белән тулыландырырга:

«7) инициатив проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы Р.Р. Ислямов